**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2021 елның «27» сентябреннән № 394

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аларны аерым туплау) тәртибен раслау турында» 2019 елның 13 февралендәге 31 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 26 июлендәге 225-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе турында» Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда контрольдә тоту чараларын үткәргән вакытта үтәлергә тиешле мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган федераль башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте норматив хокукый актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2020 елның 11 июлендәге 1036 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә каты коммуналь калдыкларны (шул исәптән аларны аерым туплау) туплау тәртибен раслау турында» 2019 елның 13 февралендәге 31 номерлы карарындагы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә каты коммуналь калдыкларны (шул исәптән аларны аерым туплау) туплау Тәртибенең 5.4 пунктындагы «Россия Федерациясе

Хөкүмәтенең «Тиешенчә булмаган җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру гражданнар тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен (яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә) раслау турында» 2010 елның 3 сентябрендәге 681 номерлы карары белән расланган» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә каты коммуналь калдыкларны (шул исәптән аларны аерым туплау) туплау тәртибен раслау турында» 2019 елның 13 февралендәге 31 номерлы карарындагы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә каты коммуналь калдыкларны (шул исәптән аларны аерым туплау) туплау Тәртибенең 1.5 пунктының 7 абзацындагы «Территориаль схема – Татарстан Республикасында калдыклар белән, шул исәптән каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендәге территориаль схема.» сүзләрен «Территориаль схема – калдыклар белән эш итү һәм каты коммуналь калдыклар белән эш итү (шул исәптән аларны аерым туплау), калдыкларны җыю, ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру һәм урнаштыру буенча схема» сүзләренә алмаштырырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://parvo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://www. novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фәсахов